| СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПИСЬМЯНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ПИСМƏН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРƏМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| --- | --- |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның «01» июне Подлесный пос. № 11

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмəн авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендəге 30 номерлы карары белəн расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмəн авыл җирлеге» муниципаль берəмлегендə Бюджет төзелеше һəм бюджет процессы турындагы нигезлəмəгə үзгəрешлəр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һəм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгəрешлəр кертү һəм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтəлеше үзенчəлеклəрен билгелəү турында» 2021 елның 29 ноябрендəге 384-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгəрешлəр кертү турында» 2022 елның 26 мартындагы 65-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендə, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмəн авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмəн авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге Советының 2019 елның 29 октябрендəге 30 номерлы карары белəн расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Писмəн авыл җирлеге» муниципаль берəмлегендə Бюджет төзелеше һəм бюджет процессы турындагы нигезлəмəгə түбəндəге үзгəрешлəр кертергə:

6 статьяны түбəндəге эчтəлекле унберенче яңа абзац белəн тулыландырырга:
«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;
унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга;

23 статьяда:
13 абзацта «муниципаль гарантиялəр буенча» сүзлəрен «,муниципаль гарантиялəрдəн килеп чыга» сүзлəренə алмаштырырга;
19 абзацта «чагылдырылган муниципаль гарантиялəр буенча» сүзлəрен «,чагылдырылган муниципаль гарантиялəрдəн килеп чыга торган.» сүзлəренə алмаштырырга;
23 абзацны төшереп калдырырга;

27 статьяның 2 өлешендə «, һəм Җирлекнең бурыч йөклəмəлəрен түлəү күлəмнəрен раслау» сүзлəреннəн соң «, инфраструктур проектларны гамəлгə ашыруны финанс белəн тəэмин итүгə җəлеп ителгəн бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмаган калдыгы күлəменнəн тыш,» сүзлəре белəн тулыландырырга;

27 статьяның 3 өлешендә «,һәм Җирлекнең бурыч йөкләмәләрен түләү күләмнәрен раслау» сүзләреннән соң «инфраструктур проектларны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының файдаланылмаган калдыгы күләменнән тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Писмән авылы, Гагарин урамы, 5 йорт, Иске Писмән авылы, Үзәк урам 50 йорт (авыл мәдәният йорты) адреслары буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Писмән авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Р.В.Насретдинов